КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 июль г.Казань № 803

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарында һәм күләмнәрендә:

1 пунктта «1 917,26» саннарын «2 102,42» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «1 119,27» саннарын «1 227,37» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 8 июль, 803 нче
карары редакциясендә)

2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш башкару исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 20 456 027 |
| 2. | Архив документларының сакланышын тәэмин итү һәм аларны исәпкә алу | 41 934 856 |
| 3. | Архив документларының тасвирламасын эшләү, аларның белешмә һәм эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә характерындагы мәгълүмат бирү басмаларын әзерләү | 10 228 014 |
| 4. | Архив документларындагы дәүләт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итә торган мәгълүматларны саклау һәм аларның сер булуын билгеләнгән тәртиптә бетерүне оештыру | 4 091 205 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәне документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм методик ярдәм күрсәтү | 6 136 808 |
| 6. | Архив документларының белешмә һәм эзләү чараларыннан «ерактан торып» файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 7 159 610 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат чараларын, бастырып чыгару һәм күргәзмә проектларын тормышка ашыру | 10 228 014 |

___________________________